МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от 20.09.2024 № 73

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирү тәртибен раслау турында

Боерык бирәм:

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирүнең кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге җитәкчесенә:

әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгән әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.Х.Садыйковка йөкләргә.

Министр Ф.М.Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл
хуҗалыгы
министрлыгының
2024 елның « 20 нче»
сентябрь № 73
боерыгы белән расланды

**Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип (алга таба – Тәртип) нигезендә «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 220-ФЗ номерлы федераль закон) 19 статьясы нигезендә элегрәк даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы бирелгән юридик затларга, шәхси эшкуарларга яки гади ширкәтнең вәкаләтле катнашучыларына (алга таба – Мөрәҗәгать итүче) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирү кагыйдәләре билгеләнә.

2. Таныклык яисә маршрут картасы югалган яисә алар бозылган очракта, Мөрәҗәгать итүче таныклыкның дубликатын һәм (яисә) маршрут картасы дубликатын сорап Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлыкка) мөрәҗәгать итә.

3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча таныклык дубликатын бирү турында гариза һәм (яисә) Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча маршрут картасы дубликатын бирү турында гариза тапшыра (җибәрә).

4. Таныклык дубликатын бирү турында гариза һәм (яисә) маршрут картасы дубликатын бирү турында гариза гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы тарафыннан тапшырылган очракта, гаризага гади ширкәттә катнашучылар турында белешмәләр Тәртипкә 3 нче кушымтада

каралган форма буенча һәм гади ширкәт шартнамәсенең күчермәсен теркәп бирелә.

5. Таныклык дубликатын бирү турында гариза һәм (яисә) маршрут картасы дубликатын бирү турында гариза, шулай ук Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән хәлләр очрагында гади ширкәттә катнашучылар турында белешмәләр һәм гади ширкәт шартнамәсе күчермәсе Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка түбәндәгечә җибәрелә:

1) кәгазьдә шәхсән яисә почта аша хат итеп;

2) Россия Федерациясенең «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законы нигезендә Министрлыкның рәсми электрон почта адресына яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

6. Таныклык дубликатын һәм (яисә) маршрут картасы дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигез булып таныклыкның һәм (яисә) маршрут картасының гамәлдә булу срогы тәмамлану тора.

7. Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлыкта кабул ителгән көннән алып өч календарь көн эчендә теркәлә.

8. Мөрәҗәгать итүчегә таныклык дубликатын һәм (яисә) маршрут картасы дубликатын бирү Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлыкта теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

9. Таныклык дубликатын һәм (яисә) маршрут картасы дубликатын бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Мөрәҗәгать итүчегә таныклык дубликатын бирүдән баш тарту турында хәбәр һәм (яисә) маршрут картасы дубликатын бирүдән баш тарту турында хәбәр, баш тарту сәбәпләрен дәлилләп, Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлыкта теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә җибәрелә.

10. Таныклык дубликаты һәм (яисә) маршрут картасы дубликаты 220-ФЗ номерлы федераль законның 27 статьясындагы 3 өлеше һәм 28 статьясындагы 3 өлеше нигезендә формалары транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган бланкларда бирелә.

11. Таныклык дубликаты һәм (яисә) маршрут картасы дубликаты бланкларына Министрлык тарафыннан бирелгән таныклыкның һәм маршрут картасының югалган яисә бозылган бланкларындагы белешмәләргә тәңгәл белешмәләр кертелә. Таныклык дубликаты яисә маршрут картасы дубликаты бланкларын тутырганда түбәндәге язулар күрсәтелә:

таныклык дубликаты бланкында - «ТАНЫКЛЫК ДУБЛИКАТЫ сериясе 000000 № 000000» уртада тигезләп, аерым юлда;

маршрут картасы дубликаты бланкында - «МАРШРУТ КАРТАСЫ ДУБЛИКАТЫ сериясе 000000 № 000000» уртада тигезләп, аерым юлда.

12. Бирелгән таныклык дубликатының һәм маршрут картасы дубликатының күчермәләре Министрлыкта саклана.

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирү тәртибенә 1 нче кушымта

**Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын бирү хакында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын бирүегез турында үтенәм:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестры нигезендә маршрутның тәртип номеры һәм исеме )

элек бирелгән урынына ____________________________________________________

______________________________________________________________________________

(атама – юридик зат өчен, Ф.И.А. – шәхси эшкуар, гади ширкәтнең вәкаләтле катнашучысы өчен, гади ширкәтнең атамасы, ИНН)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(урнашу урыны – юридик зат өчен, яшәү урыны – шәхси эшкуар, гади ширкәтнең вәкаләтле катнашучысы өчен)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

таныклык сериясе ___________ № _________________

чөнки ____________________________________________________________

(бозу, югалту)

| ______________________ | ________________ | ________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (Ф.И.А.) |

МУ (булган очракта)

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирү тәртибенә 2 нче кушымта

**Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты картасы дубликатын бирү турында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты картасы дубликатын бирүегез турында үтенәм:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестры нигезендә маршрутның тәртип номеры һәм исеме )

элегрәк бирелгәне урынына алмашка ______________________________

______________________________________________________________

(атама – юридик зат өчен, Ф.И.А. – шәхси эшкуар, гади ширкәтнең вәкаләтле катнашучысы өчен, гади ширкәтнең атамасы, ИНН)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(урнашу урыны – юридик зат өчен, яшәү урыны – шәхси эшкуар, гади ширкәтнең вәкаләтле катнашучысы өчен)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

карта сериясе ____________ № ___________________

чөнки ______________________________________________________

(бозу, югалту)

___________________________ ____________________ ____________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.)

МУ (булган очракта)

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы дубликатын бирү тәртибенә 3 нче кушымта

**Гади ширкәттә катнашучылар турында белешмәләр**

______________________________________________
(гади ширкәтнең атамасы)

| т/с | Исеме (Ф.И.А.) | Салым түләүченең тәңгәллек номеры | Урнашу урыны, яшәү урыны, почта адресы, электрон почта адресы, элемтә телефоны |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |